
# Син дә татарча сөйләш!

**Еллар узган саен бу исем ешрак телгә алына. Тукай шәхесе елдан ел калкурак күренә. Татар халкының даһи улына якты дөньяда озак яшәү насыйп булмый. Әмма ул башкарган эшләр гасырларга тиң.**

***Димәк, Тукай яши, Тукай – үлемсез***



**АПРЕЛЬ, 2018**



# Һади Атласи исемендәге татар гимназиясендә укучыларның “Ачыш” дип исемләнгән XXIII фәнни-гамәли конференциясе





Башлангыч белемне әтисе мәктәбендә ала. Аннары атаклы Буа мәдрәсәсенә укуын дәвам итә. Белемнәрен тирәнәйтү нияте белән Оренбургның Каргалы бистәсендәге Гани бай Хөсәенов оештырган укытучылар хәзерләүче семинариягә укырга керә һәм аны 1908 елда тәмамлый. Аннары Һади Атласи Буа мәдрәсәсенә кайтып, уку-укыту эшләрен яңартуга күп көч куя, киң җәмәгать эшчәнлеге дә алып бара.

1903 елда Һади Атласины Бөгелмә өязе Әлмәт авылы (хәзерге Әлмәт шәһәре) мәдрәсәсенә имам һәм мөдәррис итеп чакыралар. Ул монда кызлар мәктәбе дә ача. Диния нәзарәте каршында имтихан тотып имамлыкка указ ала.

1907 елда Һади Атласины Самара губернасыннан Дәүләт Думасына депутат итеп сайлана.

1905 — 1910 елларда Һади Атласи зур тырышлык куеп тарихи материаллар җыю, тарихи әдәбият өйрәнү өстендә эшли. Шул хезмәтләренең җимешләре буларак, 1911 — 1914 елларда бер-бер артлы аның "Себер тарихы", "Казан ханлыгы", "Сөен-бикә" исемле тарихи әсәрләре басылып чыга. 1913 елда ул Казан университеты каршындагы "Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте"нең тулы вәкаләтле әгъзасы буларак сайлана.

Беренче бөтендөнья сугышы, 1917 ел Февраль һәм Октябрь революцияләре, гражданнар сугышы елларында Һади Атласи гаиләсе белән Бөгелмәшәһәрендә тора. 1920 елдан 1929 елга кадәр ул Бөгелмәдә икенче баскыч мәктәбендә тарих һәм немец теле укытучысы булып эшли.

1929 елда аны бернинди гаепсезгә кулга алып, ун елга Соловкидагы каторгага сөрәләр.

1934 елда, Архангилдән Бөгелмәгә кайтып ярты ел торгач, Һади Атласи гаиләсе белән Казанга күчеп килә. 1936 елда ул тагын кулга алына. 1936 елныңавгустыннан 1937 елның маена кадәр аңардан 16 допрос алганнар. 1937 елның 23-28 октябрендә Менжинский исемендәге клубта Идел буе хәрби округы хәрби трибуналының ябык утырышлары "Атласовщина" дип аталган эшне карый. Хәрби трибунал буенча 9 кеше: Һ.М.Атласов, Р.Я.Яруллин, К. К. Туйкин, Ф. К. Туйкин, Б. Ф. Фаттахов, Г. А. Алтынбаев, К. Л. Исхаков, С. Ш. Уразманов, 3. Б. Фәттахов атып үтерелергә хөкем ителгән.

1958 елда Һади Атласиның гаепсезлеге танылa һәм ул реабилитацияләнә.



Министерство образования и науки Республики Татарстан

Государственное автономное учреждение «Республиканский олимпиадный центр»

Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение татарская гимназия №14 имени Хади Атласи

ДИПЛОМ

II степени

Награждается участник I межрегиональных юношеских чтений имени Хади Атласи

ученица 9а класса МБОУ СОШ №6 г Бугульмы РТ Муратова Динара

Научный руководитель: Надршина Г.М.

Директор ГАОУ «Республиканский олимпиадный центр» Г.Д. Зарипова

Директор МБОУ татарской гимназии №14 имени Хади Атласи Ф.К. Гайнуллин



Министерство образования и науки Республики Татарстан

Государственное автономное учреждение «Республиканский олимпиадный центр»

Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение татарская гимназия №14 имени Хади Атласи

ДИПЛОМ

I степени

Награждается участник I межрегиональных юношеских чтений имени Хади Атласи

Научный руководитель:

Директор ГАОУ «Республиканский олимпиадный центр» Г.Д. Зарипова

Директор МБОУ татарской гимназии №14 имени Хади Атласи Ф.К. Гайнуллин

07.04.2018

# “Мин татарча сөйләшәм” акциясе дәвам итә.....

Укытучылар безне рус мәктәбендә укысак та, татар теленә, татар халкының рухи, әдәби мирасына ихтирам мохитында тәрбияли. Бер-беребез белән матур итеп татарча аралашабыз. Саф татар телендә төрле чаралар, очрашулар үткәрәбез. Халыкара телләр бәйрәмен дә укытучыларыбыз белән бергә шундый күңелле итеп оештырдык. Сүзлекләр, плакатлар ясадык. Сыйныфлар арасында татар телен иң яхшы белүче, иң матур итеп сәнгатьле укучы бәйгеләрендә көч сынаштык. Татарстан тарихы турындагы әңгәмәләрдә тагын бер тапкыр белемнәребезне барладык, җырлар җырладык, шигырьләр сөйләдек. Барлык чараларда да татар халык язучысы Гомәр Бәшировның “Телсез халык үзе дә була алмый, халыксыз – тел дә юк”, дигән сүзләре кабат-кабат яңгыраш тапты. Ләкин телне бер генә көндә өйрәнеп булмый. Дистә еллар дәвамында ничә буын рус, татар балалары күңеленә бөек Тукай теленең башка халыкларга да мәгърифәт нуры таратучы бай тарихлы.

Әйдәгез, бергәләп татарча туган телебездә матур итеп сөйләшик, аңлашыйк, аралашыйк!






















# МИЛЛӘТТӘШЛӘР БЕЛӘН ОЧРАШУ









13нче апрель көнне 6нчы урта мәктәптә туган телгә багышланган төбәкара конференция узды. Конференциядә Ырынбур өлкәсе Әсәкәй районының белем бирү учреждениесе методистлары һәм мәктәп директорлары катнашты. Мәктәп директоры В.В. Парфенов, уку һәм тәрбия эше буенча директор урынбасарлары мәртәбәле кунакларны мәктәп торышы, олимпиада, БРТ күрсәткечләре белән таныштырдылар. Йосыпова Л.Ә туган тел һәм әдәбияты укытучыларының методик берләшмә эше турында сөйләде. Туган тел һәм әдәбияты укытучыларының эш күрсәткечләре куанычлы. Мәктәптә танылган әдипләрнең туган көннәре билгеләп үтелә, күренекле шәхесләр белән очрашулар уздырыла һәм алар турында матбугат битләрендә басыла.Конференциядә кунаклар белән түгәрәк өстәл артында сөйләшүләр булды. Укытучылар эш тәҗрибәләре белән уртаклаштылар.Хафизова Р.Ә “Саф хисләр юлдаш булсын” дигән мастер-класс күрсәтте.4нче сыйныф укучылары белән Хаева А.Р “Тел дәрьясы” түгәрәгенең эшен күрсәтте.Конферения ахырында укучылар көче белән әзерләнгән концерт күрсәтелде. Концерт барлык кунаклар белән бергәләшеп башкарылган “ Туган тел” җыры белән төгәлләнде.

*Г.Р. Хисамова*

*Бөгелмә муниципаль районы мәгариф идарәсенең мәгълүмати- методик үзәге методисты*














Нам дан во владение
самый богатый,
меткий, могучий и
поистине волшебный
русский язык.
Г. Паустовский









*...И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!*
*Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы…*


Габдулла Тукай 1886 елда Арча янындагы кечкенә Кушлавыч авылында дөньяга килгән. Ул өч яшендә тома ятим кала. Кыска гына гомерендә бик күп авырлыклар күрсә дә, көрәш өчен, рухланып хезмәт итү өчен үзендә һәрвакыт көч таба. Шигырьләрендә туган ягына, халкына һәм туган теленең матурлыгына мәдхия укый.
Шагыйрь 1913 елда 27 яшендә дөнья белән саубуллаша. Аның бик күп әсәрләре театр сәхнәләрендә һәм музыкада яшәүләрен дәвам итәләр. Г. Тукай Казанда җирләнгән.




Габдулла Тукай
(1886- 1913)
ВОДЯНАЯ
ТУКАЙ


Габдулла Тукай
(1886- 1913)
Тукай халык күңелендә










Наша гордость





